**Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.10.2010 ел, №210-ФЗ Федераль закон нигезендә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгарырга (1 нче кушымта).
2. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 20.08.2019 № 561 карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карарның үтәлешен Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасимов**